**Зеленодол муниципаль район Советы**

**Карар**

**4 март 2019 ел** **№367**

Татарстан Республикасының Зеленодол муниципаль район Советы 2018 елның 29 мартында 279 номерлы расланган карары белән, Татарстан Республикасының «Зеленодол муниципаль район» муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, «Муниципаль берәмлекләр уставын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә Зеленодол муниципаль район Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасының Зеленодол муниципаль район Советы 2018 елның 29 мартында 279 номерлы расланган карары белән, Татарстан Республикасының «Зеленодол муниципаль район» муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 6 маддә.:

1.1) 1 өлешенең 5нче бүлегендә “Район чикләрендә чикләреннән тыш җирле билгеләнештәге автомобиль юлларын сакланышы өчен” дигән сүзләрдән соң, “, юл хәрәкәтен оештыру” дигән сүзләрне өстәргә;

1.2) 1 өлешендә 8 бүлегендә “хокуклары” дигән сүздән соң «аз санлы төп халкы һәм башкаларның» дигән сүзләрне өстәргә;

1.3) 1 өлешенең 16нчы бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«16) Район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплауны (шул исәптән аерып туплау) җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;»;

1.4) 1нче өлешенең 17нче бүлегендә «индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объекты яки җир кишәрлегендә бакча йорты урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы турын да хәбәрнамә җибәрүе, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларга туры килмәве яки индивидуаль торак төзелеше объекты яисә җир кишәрлегендә бакча йорты параметрларына туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрергә, индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки

үзгәртеп корылган объектының индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортларын төзегәндә яки үзгәртеп корганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында хәбәрнамәләр яисә Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән бинаны сүтү турында карар кабул ителү, максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый торган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген алу, үз белдеге белән төзелгән биналарны сүтеп алу яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карарлар;» дигән сүзләр белән тулыландырырыга;

1.5) 3нче өлешенең 5нче бүлегендә «җирлек чигендәге җирле билгеләнештә булган автомобиль юлларының сакланышы өчен» дигән сүзләрдән соң «юл хәрәкәтен оештыру» дигән сүзләр белән тулыландырырга,»;

1.6) 3нче өлешенең 12нче бүлегендә «шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объекты яки җир кишәрлегендә бакча йорты урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы турында хәбәрнамә җибәрүе, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларга туры килмәве яки индивидуаль торак төзелеше объекты яисә җир кишәрлегендә бакча йорты параметрларына туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрергә, индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объектының индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортларын төзегәндә яки үзгәртеп корганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында хәбәрнамәләр яисә Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә ике авыл арасындагы территориядә урнашкан, үз белдеге белән төзелгән бинаны сүтү турында карар кабул ителү, максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый торган яки аны тиешле билгеләнгән шартларга туры китерү, максатчан билгеләнештә кулланмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген алу, үз белдеге белән төзелгән биналарны сүтеп алу яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карарлар;» дигән сүзләр белән тулыландырырыга;

2) 7 маддәнең 1нче өлешендә 13нче бүлеген киләсе эчтәлек белән тулыландырырга:

«13) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән «Кулланучылар хокукы турында»гы 2300-1нче Законында каралганча, кулланучыларның хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашырырга»;

3) 18нче маддә.:

3.1) 2нче өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Ачык тыңлаулар үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы халык, район Советы, район Башлыгы яки районның башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча уздырыла.

Халык, яки район Советы инцнативасы буенча уздырылучы ачык тыңлаулар район Советы тарафыннан билгеләнә, үз вәкаләтләрен Район Башлыгы контракт нигезендә гамәлгә ашыручы район Башлыгы яки районның башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча уздырыла.»;

3.2) 10нчы өлешендә «хәзерге маддәнең 3нче өлешендә күрсәтелгән проект һәм сораулар буенча» дигән сүзләрне юк итәргә,»;

4) 41нче маддәнең:

4.2) 5нче өлешенең 1нче бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә катнашудан тыш, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюзда, съезда (конференция) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтеннән тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте актлы нигезендә коллегиаль орган оештыру эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; оешманың идарә итү һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру, учредителе (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү органнарында муниципаль хокукый актларга туры китереп, оешма учредителе исеменнән муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен чагылдыру яки муниципаль милектә булган акцияләр белән идарә итү (устав капиталында өлешләп катнашу); федераль законда каралганча башка очракларда;»;

5) 44нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге 14нче өлеш белән тулыландырырга:

«Район башлыгына карата Район Советы аны отставкага җибәрү турында карар кабул иткәннән соң, ул гариза белән ризасызлык белдереп, әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң, 10 көн эчендә судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Суд гариза кергән көннән алып, 10 көннән дә соңга калмыйча тикшереп, карар кабул итәргә тиеш.»;

6) 46 маддәнең 7нче өлешенең 1нче бүлеге. Яңа редакциядә бәян итү:

«1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә катнашудан тыш, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз, съезда (конференция) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтеннән тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте актлы нигезендә коллегиаль орган оештыру эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; оешманың идарә итү һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль

берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру, учредителе (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү органнарында муниципаль хокукый актларга туры китереп, оешма учредителе исеменнән муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен чагылдыру яки муниципаль милектә булган акцияләр белән идарә итү (устав капиталында өлешләп катнашу); федераль законда каралганча башка очракларда;»;

7) 50нче маддадә:

7.1) мадддәнең 1 өлеше 3 бүлеге 17 абзацны «шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объекты яки җир кишәрлегендә бакча йорты урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы турында хәбәрнамә җибәрүе, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларга туры килмәве яки индивидуаль торак төзелеше объекты яисә җир кишәрлегендә бакча йорты параметрларына туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрергә, индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объектының индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортларын төзегәндә яки үзгәртеп корганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында хәбәрнамәләр яисә Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә ике авыл арасындагы территориядә урнашкан, үз белдеге белән төзелгән бинаны сүтү турында карар кабул ителү, максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый торган яки аны тиешле билгеләнгән шартларга туры китерү, максатчан билгеләнештә кулланмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген алу, үз белдеге белән төзелгән биналарны сүтеп алу яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карарлар;» дигән сүзләр белән тулыландырырыга;

7.2) 1нче өлешнең 4нче бүлегендә 3нче абзац. «район чикләрендә торак пунктлар

чикләреннән тыш җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» дигән сүзләрдән соң, «юл хәрәкәтен оештыру» дигән сүзләрне өстәргә;

7.3) 1нче өлешенең 5нче бүлегенең 18нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«-район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау), җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;»;

7.4) 1нче өлешенең 7нче бүлегендә 11нче абзацын «хокук» сүзеннән соң «аз санлы төп халыклар һәм башкаларның» сүзе белән тулыландырырга;

7.5) 2нче өлешенең 14нче абзацын түбәндәгене өстәргә:

«-) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән “Кулланучылар хокукы турында»гы 2300-1нче Законында каралганча,

кулланучыларның хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашырырга»;

8) 51 маддәне алдагы эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәдәге вазифаи затларның эшчәнлеген планлы һәм планнан тыш тикшерү турындагы мәгълүмат, аларның нәтиҗәләре һәм табылган тәртип бозуларны юк итү Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган тикшерүләр бердәм реестрына кертү һәм кагыйдәләргә ярашлы рәвештә формалаштыру нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиеш.»;

9) 52нче маддәнең:

9.1) 1нче өлешенең 4нче бүлегендә 4нче абзацны яңа редакциядә бирергә:

«-торак биналарны торак булмаган биналарга һәм торак булмаган биналарны торак биналарга күчерү турында карарларны тиешле тәртиптә кабул итә, күп фатирлы йортта биналарны яңадан үзгәртеп кору һәм яңадан планлаштыруны килештерә, тиешле тәртиптә яши торган муниципаль торак фондын яшәргә яраксыз дип таный»;

9.2)1нче өлешенең 4нче бүлегендәге җиденче абзацта итәргә:

«шәһәр җирлеге чикләрендә җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» дигән сүзләрдән соң, «юл хәрәкәтен оештыру» дигән сүзләрне өстәргә;

9.3) 1нче өлешенең 6нчы бүлегендә икенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«-каты коммуналь калдыкларны туплауда (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортировкалауда катнашу;

9.4) 2нче өлешенең унөченче абзацында «караучысыз хайваннарны тоту һәм асрау» дигән сүзләрне «хуҗасыз яшәүче хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлек» дип алыштырырга;

9.5) 2нче өлешне түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«- Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән “Кулланучылар хокукы турында”гы 2300-1нче Законында каралганча, кулланучыларның хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашырырга»;

10) 8нче1 маддәнең:

10.1) 3нче өлешен икенче абзац белән түбәндәге эчтәлекне өстәргә: «Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын һәм килешүләрен рәсми бастыру (халыкка хәбәр итү) өчен интернет челтәре басмаларын кулланырга хокуклы. Әгәр дә муниципаль хокукый актларның тулы тексты рәсми интернет басмасында зур график һәм таблица кушымта буларак бастырыла (урнаштырыла) икән, басма төстә кирәк булмый.»;

10.2) 12нче өлеш белән түбәндәге эчтәлекне өстәргә:

«12. Җирле үзидарә органнары арасындагы килешүләрне бастыру (халыкка хәбәр итү) әлеге Уставның 81нче маддәсе 3нче өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

11) 88нче маддәнең.:

11.1) 1 өлешенң 2нче бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«Шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш; түләүсез нигездә профсоюз органы белән идарә итүдә катнашудан тыш; шул исәптән сайлау комиссиясе аппаратында җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек, милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу; коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу; (сәяси партиядән һәм профсоюз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, җирле үзидарә сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына эшкә алучы вәкиле рөхсәте белән керү, ул муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган), җирле үзидарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә җирле үзидарә мәнфәгатьләрен бушлай тәкъдим итүдән тыш, гамәлгә куючы (акционер) , муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) оештыру яки идарә итү вәкаләтләрен җирле үзидарә исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә; федераль законнарда каралган башка очракларда;»

11.2)  түбәндәге эчтәлектә 4нче өлеш белән тулыландырырга:

«4. Җитәкче булып торучы муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында ихтыяҗлар конфликтына юл куймау максатыннан, билгеләнгән вазифаны башкарган вакыт аралыгында, әлеге җирле үзидарә органының сайлап куелган профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклаучы була алмый.»;

12)112нче маддәнең 2нче өлешенең беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Район Уставы, шул Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы Район Советы карары дәүләт теркәлүе узганнан соң «Интернет» мәгълүмати-коммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе юстиция Минстрлыгының «Россия Федерациясендә хокук һәм норматив актлар» порталында график сурәтләр рәвешендә (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф) муниципаль берәмлекләр уставлары дәүләт реестрына кертелергә тиеш.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән закон тәртибендә дәүләт теркәлүен узу өчен юлларга.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәлүе узганнан соң «Зеленодольская правда» газетасында бастырырга һәм шулай ук, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокук мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының

муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодол муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмаларының гомуми принциплары турында»гы (06.10.2003 ел, №131-ФЗ) Федераль законының 44нче маддәсенең 8нче өлешенә яраклы рәвештә үз көченә керүен расларга.

5. Әлеге карарның үтәлеше буенча контрольне Зеленодол муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодол муниципаль**
**район башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В.Тыгин**